РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

САБИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН

САТЫШЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ

422070, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Сатышево, ул.Ленина, 17Б
тел. (84362) 2-24-16

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САТЫШ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422070, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Сатыш авылы, Ленин урам,17Б йорт
тел. (84362) 2-24-16

e-mail: Sat.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
22.01.2024

КАРАР
№7

Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитетының 2019 елның 7 маендагы 32 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитеты баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитетының «Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 7 маендагы 32 номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Сатыш авыл башкарма комитетының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлектәге 7 пункт белән тулыландырырга:

«7. Исәп-хисап чорында хезмәт дисциплинасын бозган өчен дисциплинар һәм матди җаваплылыкка тартылган түбәндәге очракларда бухгалтерларга премияләр түләнми:

– сәбәпсез эш калдыру;

- соңга калу;
- турыдан туры җитәкченең боерыгын үтәмәү;
- алкоголь, наркотик, токсик исерек хәлдә эшкә килү;
- эш бирүченең милкен югалту яки бозу;
- билгеләнгән хезмәт нормаларын үтәмәү, йөкләмәләрне үтәү срокларын бозу.

Бухгалтерда алынмаган дисциплинар җәза булганда премия күләме 50% ка кими.

Әгәр премия түләнгәннән соң хокук бозулар ачыкланса, премиядән мәхрүм итү хокук бозулар ачыкланган исәп-хисап чорында башкарыла.».

2 Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Сатыш авыл җирлеге рәсми сайтында hhttp://saby.tatarstan.ru/satish адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Сатыш авыл җирлеге башлыгы Ф.Ф.Шафигуллин